РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д. 47,
с. Муртыш-Тамак
423358
Телефон: 4-52-05

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОРТЫШТАМАК АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 47 йорт,
Мортыштамак авылы,
423358
Телефон: 4- 52-05

ОГРН 1061687003058 ИНН/КПП 1636005567/163601001 ОКАТО 92253840000

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.01.2021 ел №1

### Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл жирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 слның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм жирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6424,98 сум күләмендә курсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2019 елның 14 мартындагы 5номерлы карарын һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2020 елның 31 январендәге 1 нче номерлы карарын уз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO. TATARSTAN.RU) Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Мортыштамак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: И.Н. Һалиуллин

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3700,00 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1336,39 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1387,79 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2021 елның 29 гыйнварындагы
1 номерлы карарына 2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Кәфенләү | 1234,23 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2461,43 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1336,39 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1392,93 |
| Барлыгы | 6424,98 |